ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20.02.2025 г. Заинск №79

**«Муниципаль мөлкәт реестрыннан исәпкә алу объектлары турында мәгълүмат бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында»**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 15 августындагы 1415 номерлы «РФ Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» карарына таянып, Зәй муниципаль районы Уставы белән, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Муниципаль мөлкәт реестрыннан исәпкә алу объектлары турында мәгълүмат бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын кушымта нигезендә расларга.
2. Үз көчен югалткан дип танырга:

2.1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 22 декабрендәге 776 номерлы «Муниципаль мөлкәт реестрыннан исәпкә алу объектлары турында мәгълүмат бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» карары.

2.2. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 8 августындагы 449 номерлы «Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 22 декабрендәге 776 номерлы карары белән расланган муниципаль мөлкәт реестрыннан исәпкә алу объектлары турында мәгълүмат бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында" карары.

3. Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый үсеш, сәнәгать, сәүдә, эшкуарлыкка ярдәм буенча урынбасарына йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Э.Э.Галеев**

Р.Р. Шәйхиев
2 80 31